**ГЛАВА**
**МАСЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422647, с. Масловка,
ул. Центральная, дом 13

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МАСЛОВКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ**
**БАШЛЫГЫ**

422647, Масловка авылы,
Центр урамы, 13 нче йорт,

Тел.: (84361) 253 55, факс: (84361) 253 55, e-mail: Masl.RS@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.05.2025г. с. Масловка № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге башлыгының 2011 елның 30 апрельдагы «Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советында һәм Башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибе хакында» 49а номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив актны Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә КАРАР БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге башлыгының 2011 елның 30 апрельдагы «Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советында һәм Башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибе хакында» 49а номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советында һәм Башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибен кушымтада бирелә торган яңа редакциядә расларга;

1.2. Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советында һәм Башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар

кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турындагы хәбәрнамәне карау комиссиясе составын кушымтада бирелгән яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авылы, Үзәк урамы, 13 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге башлыгы А.И.Егоров

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 13 майдагы 1 номерлы карары белән расланды

Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советында һәм Башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибе

1. Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советында һәм Башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә (алга таба - яллаучы) хәбәр итү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру максатларында эшләнде.

2. Әлеге Тәртип муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында аларга мөрәҗәгать итү фактлары турында Яллаучыга хәбәр итүнең, шулай ук мондый хәбәрнамәләрне теркәүнең һәм алардагы мәгълүматларны тикшерүне оештыруның мәҗбүри процедурасын билгели.

3. Коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында муниципаль хезмәткәргә нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итүенең барлык очраклары турында яллаучы вәкиленә хәбәрнамә (алга таба – Хәбәрнамә) муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан җирлекнең Башкарма комитетына әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада каралган рәвеш буенча мөрәҗәгать иткән көннән соң ук килүче эш көненнән (көннәреннән) соңга калмыйча тутырыла һәм тапшырыла, ял һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән гайре.

Хәбәрнамәдәге мәгълүматлар исемлеге әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада китерелә.

Хәбәрнамәгә муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү шартларын (сәбәпләрен) раслый торган барлык булган материаллар теркәлә.

4. Муниципаль хезмәткәр хезмәт вазыйфаларын башкармаган очракта һәм эш урыныннан читтә булганда, аны коррупциячел хокук бозуга тарту факты турында ул яллаучыга мөмкин булган теләсә нинди элемтә чаралары буенча хәбәр итәргә, ә хезмәт урынына килгәч, тиешле хәбәрнамәне язма рәвештә рәсмиләштерергә тиеш.

Муниципаль хезмәткәр үзен коррупциячел хокук бозуга тарту фактлары турында прокуратура органнарына һәм башка дәүләт органнарына хәбәр итә ала, бу хакта, шул исәптән хәбәрнамәнең эчтәлеген күрсәтеп, яллаучыга хәбәр итәргә тиеш.

5. Хәбәрнамә яллаучы тарафыннан ул килеп ирешкән көнне муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында Яллаучының хәбәрнамәләрне теркәү Журналында (алга таба – Журнал) әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтада каралган рәвештә теркәлә. Хәбәрнамәне теркәүдән баш тарту рөхсәт ителми.

Муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәрнамәләрне теркәү журналы битләре номерланган, тегелгән һәм мөһер белән беркетелгән (расланган) булырга тиеш.

Билгеләнгән тәртиптә теркәлгән хәбәрнамәнең күчермәсе муниципаль хезмәткәргә кулына имза куйдырып бирелә. Муниципаль хезмәткәргә тапшырылырга тиешле хәбәрнамәнең күчермәләрендә түбәндәгеләр күрсәтелә: хәбәрнамәне теркәү датасы һәм теркәү номеры; әлеге хәбәрнамәне теркәгән затның фамилиясе, инициаллары һәм вазыйфасы.

6. Журнал анда соңгы хәбәрнамә теркәлгәннән соң 5 ел дәвамында саклана, шуннан соң архивка тапшырыла.

7. Хәбәрнамә теркәлү журналында теркәлгәннән соң, андагы мәгълүматларны тикшерүне алга таба оештыру максатыннан, ул шул ук эш көне дәвамында яллаучыга карауга тапшырыла.

Яллаучы хәбәрнамәне карау йомгаклары буенча Хәбәрнамәдәге мәгълүматларны тикшерүне оештыру турында карар кабул итә.

8. Хәбәрнамәләрдәге мәгълүматларны тикшерү муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турындагы хәбәрнамәләрне карау комиссиясе тарафыннан уздырыла.

9. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәрнамәләрне карау буенча комиссия хәбәрнамә җибәргән муниципаль хезмәткәрдән язма аңлатмалар ала, хезмәткәрне коррупциячел гамәлләр кылуга этәргән шартларны (сәбәп, хәлләрне) билгели, компетенция кысаларында муниципаль хезмәткәр тапшырган мәгълүматны һәрьяклап карау өчен кирәкле башка чараларны гамәлгә ашыра.

10. Тикшерү хәбәрнамә теркәлгәннән соң утыз эш көне эчендә үткәрелә.

11. Уздырылган тикшерү нәтиҗәләре буенча хәбәрнамә, тикшерү материалларын теркәп, прокуратура органнарына яисә башка дәүләт органнарына мәгълүмат җибәрү турында карар кабул итү өчен яллаучыга тапшырыла.

Теркәлгән хәбәрнамәләр һәм алардагы белешмәләрне тикшерү материаллары муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында яллаучыга мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәрнамәләрне карау комиссиясе докладыннан соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Башкарма комитетында саклана.

12. Яллаучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан коррупциячел хокук бозуны кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында, нинди дә булса затларны коррупциячел хокук бозуларны кылуга этәрү максатларында хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә башка муниципаль хезмәткәрләргә мөрәҗәгать итү фактлары хакында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә), прокуратура органнарына яисә башка дәүләт органнарына хәбәр иткән муниципаль хезмәткәрне яклау чаралары күрелә, муниципаль хезмәткәргә аны хаксыз рәвештә эштән азат итүне булдырмый торган гарантияләрне тәэмин итү, түбән вазыйфага күчерү, премия күләменнән мәхрүм итү яисә киметү, отпуск вакытын күчерү, муниципаль хезмәткәргә тапшырылган хәбәрнамәне карау чорында дисциплинар җаваплылыкка тарту өлешендә.

13. Муниципаль хезмәткәрнең яллаучы вәкиленә аңа билгеле булган коррупциячел хокук бозулар фактлары турында хәбәр итү буенча вазыйфаи (хезмәт итү урынындагы) бурычын үтәмәве яисә мондый фактларны яшереп калу аны муниципаль хезмәттән азат итүгә яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкның башка төрләренә җәлеп итүгә китерә торган хокук бозу була.

Балык Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге
Башкарма комитетында муниципаль
хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар
кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү
фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә
хәбәр итү Тәртибенә
1 нче кушымта

# ХӘБӘРНАМӘ

(кемгә)
______________________________________

кемнән ___________________________________
(муниципаль хезмәткәрнең Ф.И.А.и.,
вазыйфасы, структура бүлеге)

1. Мине коррупцион хокук бозуга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү факты турында хәбәр итәм____________________________________________________________
(Ф.И.А.и., вазыйфасы, барлык билгеле булган мәгълүматлар хокук бозуга этәрүче физик, юридик зат турында)
__________________________________________________________________________.
___________________________________________________________________________

2. Минем тарафтан хокук бозуга этәрү түбәндәгеләрне тормышка ашыру максатларында башкарылды
________________________________________________________________________
(фаразланган хокук бозуның асылы күрсәтелә)

3. Хокук бозуга этәрү түбәндәге юл белән башкарылды_____________
__________________________________________________________________________.
(этәрү, тарту ысулы: ришвәт, янау, алдау һ. б.)

4. Хокук бозуга тарту, этәрү түбәндәге вакытта булды:
20__ елның ______ көнендә ___ сәг. ____ минутта
________________________________________________________________________.
(адрес)

5. Хокук бозуга этәрү түбәндәгечә ясалды ___________________________
__________________________________________________________________________.
(этәрү, тарту шартлары: телефон аша сөйләшеп,
шәхсән очрашып, почта һәм башкалар)
___________________________________________________________________________

_____________________________
(хәбәрнамәне тутыру датасы)
(имза)

Хәбәрнамә журналда теркәлде:
"__ " ________ 20__ел, N ______
______________________________________
(җаваплы затның Ф.И.А.и., вазыйфасы (эш урыны))

Балык Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге
Башкарма комитетында муниципаль
хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар
кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү
фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә
хәбәр итү Тәртибенә
2 нче кушымта

**Муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы вәкиленә**
**ХӘБӘРНАМӘДӘГЕ МӘГЪЛҮМАТЛАР ИСЕМЛЕГЕ**

1. Хәбәрнамәне тутыручы муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, эш урыны (вазыйфасы), структура бүлеге _____________*(җирле үзидарә органының аталышы).*

2. Хокук бозуга этәрүче физик зат турында барлык билгеле мәгълүматлар (фамилия, исеме, атасының исеме, вазыйфасы һ.б.).

3. Фаразланган хокук бозуның асылы (вазыйфаи вәкаләтләрдән явызларча файдалану, бюджет акчаларын максатчан тотмау, вазыйфаи вәкаләтләрне арттыру, вазыйфаи зат вәкаләтләрен үзләштерү, эшкуарлык эшчәнлегендә законсыз катнашу, ришвәт алу, ришвәт бирү, хезмәт урыны буенча ялган ясау (алдау) һ.б.).

4. Хокук бозуга этәрү ысулы (сатып алу, куркыту, вәгъдә итү, алдау, көчләү һ.б.).

5. Хокук бозуга этәрү вакыты, датасы.

6. Хокук бозуга этәрү урыны.

7. Хокук бозуга этәрү шартлары (телефоннан сөйләшү, шәхсән очрашу, почта аркылы җибәрү һ.б.).

8. Хәбәрнамәне тутыру датасы.

9. Хәбәрнамәне тутырган муниципаль хезмәткәрнең имзасы, аны төзү датасы һәм вакыты күрсәтелеп.

Балык Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге
Башкарма комитетында муниципаль
хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар
кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү
фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә
хәбәр итү Тәртибенә
3 нче кушымта

Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советында һәм
Башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар
кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәрнамәләрне исәпкә алу
ЖУРНАЛЫ

| N п/п | Хәбәрнамне теркәү датасы | Хәбәрнамә бирүченең Ф.И.А.и. | Хәбәрнамә бирүченең имзасы | Бирелгән теркәү номеры | Номер бирү датасы | Теркәүченең Ф.И.А.и. | Теркәүче-нең имзасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 13 майдагы 1 нче номерлы карары белән расланды

Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советында һәм Башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турындагы хәбәрнамәне карау буенча
КОМИССИЯ СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Егоров Анатолий Иванович | Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге башлыгы, комиссия рәисе; |
| Шакирова Роза Разифовна | Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Башкарма комитеты сәркатибе, комиссия сәркатибе; |
| | Комиссия әгъзалары: |
| Никитина Елена Александровна | Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советы депутаты |